| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «САРАБИКУЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «САРАБИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

2026 елның 29 гыйнвары Сарабиккол авылы №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләр бәясен раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Сарабиккол авылы, Киров урамы, 4а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниипаль районы
« Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2026 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, сум. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 658,54 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып килү | 1 838,93 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 181,16 |
| Барлыгы | **9 678,63** |

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Җирләү һәм күмү эше турында» ФЗ-8 12 маддәсе нигезендә күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2026 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, сум. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне төрү; | 1 207,32 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2 451,21 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1 838,94 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 181,16 |
| Барлыгы | **9 678,63** |